Мәхмут Хәсәнов

УТ-МАЛАЙ

Мәхмут Хәснов

УТ-МАЛАЙ

ӘКИЯТ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1989

Борын-борын заманда яшәгән ди бер карт белән карчык. Балалары булмаган боларның. «Әһ-һ, картайган көнебездә ярдәмчебез дә юк!» — дип, еш кына уфтана торган булганнар алар.

Көннәрнең берендә карчыгы да үлеп киткән. Карт япа-ялгыз калган. Күзеннән йокысы, күңеленнән тынычлыгы качкан моның. Шулай кайгы-хәсрәткә батып, янган мич янында карт сөякләрен җылытып утыра икән ул. «Бирмәде бит ходай тәгалә берәр малай, бу кадәр авыр, бу кадәр үк ямансу да булмас иде», — дип әйткән ди карт.

Шул вакыт көтелмәгән хәл булган ди. Га-



дәттә кышкы буранлы көннәрдә генә яман аваз-лар чыгарып улаган морҗа кинәт гүләргә ке-решкән. Ул да түгел, әлеге гөрелте аша өзек-өзек сүзләр ишетелә башлаган. «Син, карт, ми-чеңне мулрак як... Ялкыннан, уттан чәчрәп оч-кындай чая малай атылып чыгар. Шулай итеп, син уллы булырсың», — дигән ди әлеге серле аваз.

Карт башта каушап калган. Көтмәгәндә тө-тен юлы — морҗа телгә килеп сөйләшә башла-сын әле, теләсә кемнең коты алыныр. Карт ни булса шул булыр дигән дә аяк очында өелеп яткан имән утыннарын алып мичкә тутырып та куйган ди.

Мич шатыр-шотыр килеп, тирә-юньгә чаткы-лар чәчеп яна да башлаган. Шундый кызган, карт, йөзен ышыклап, артка чигенеп утырырга мәҗбүр булган.

Шул чакта сәке йөзлегендә утырган картның алдына чәчрәп утлы кисәү башы килеп төшкән. Карт, киемнәре өтәлүдән куркып, әлеге күмерне учына алган да, пешмәс өчен бер кулыннан икенчесенә чөеп, яңадан дөрләп янган мичкә ат-макчы булган. Шунда әлеге утлы күмер кисәге телгә килмәсенме!

— Әти!.. Әти, бу мин, синең улың!..

Карт, бу көтелмәгән хәлдән хәйран булып, каткан да калган. Ул арада, учындагы Ут-ма-лай үзенең нәни аякларына сикереп торып та баскан ди. Сыйраклары шундый нечкә, нәкъ са-

лам юанлыгы икән. Малай, кулларын алга сузып, янә баягы сүзләрен кабатлаган:

— Әти!.. Әтием!.. Бу — мин, синең улың!..

Гаҗәпләнүеннән нишләргә дә белмичә торган карт та, ахыр чиктә, телгә килгән:

— Ай-һай, бик тә инде нәни икәнсең син...— дигән, имеш.

— Әй-йе, нәни! — дип килешкән ди Ут-малай. Аннары болай дип өстәгән ди: — Имән чикләвеге кадәр генә булсам да, имән агачының нәкъ үзе кебек нык, имән кебек түземле булырмын мин, әти...

— Ходай кушсын иде берүк, — дигән ди әти кеше.

Көннәр үтә торган. Малайлы булгач, картның да тормышы ямьләнеп киткән. «Улым, нәникәем минем!» — дип сөйгән ди карт үзенең малаен. Шулай итеп, Ут-малайның исеме дә «Нәникәй» булып калган ди.

Адәм күрке — чүпрәк ди бит. Иң элек карт Нәникәйгә киемнәр юнәтеп кидерткән. Көнбагыш кабыгы кадәрле генә итеп башмаклар тегеп биргән. Ә шук малай Нәникәй, түбәтәй урынына, башына имән чикләвеге оясын гына киеп куйган ди.

Ул арада яз да килеп җиткән. Карт басуга эшкә чыгарга җыена башлаган. Ә терчән Нәникәй һаман этисе тирәсендә чуала икән.

— Эти! Этием, мин дә синең белән барам, яме? — дип сөйләнә ди үзе.

— Улым, син анда нишләрсең икән соң?

— Сиңа булышырмын, — дигән Нәникәй.

Карт көлгән рәхәтләнеп.

— И булышчым минем!.. — дип, Нәникәйне учына бастырып сөйгән ди. — Идәнгә төшкән шырпыны табып бирү яисә инәгә җеп саплау гына түгел шул ул. Җир эшкәртү ай-һай авыр эш. Иң әүвәл ат җигеп җирне сөрәсең, аннары һәйбәтләп тырмалыйсың, аннан килеп, чәчәсең...

Нәникәй этисенә әйтеп бетерергә дә ирек бирмәгән:

— Мин дә сөрермен, мин дә!.. — дигән.

Малаеның андый эшләрне барыбер булдыра

алмаячагын белсә дә, карт улының кәефен бозарга теләмәгән. Бары:

— Ярар, Нәникәем, ярар! Сөрерсең дә, тырмаларсың да... — дип әйткән ди.

Шулай итеп, басуга чыгар көн дә килеп җиткән. Таң белән торганнар болар. Нәникәйнең куанычы эченә сыймый икән. «Мин дә барам, мин дә барам!» — дип сикеренгәләп, кулларын чәбәкли икән.

Әтисе җирән кашка җигелгән арбага сука, тырма салган да, Нәникәйне тезе өстенә утыртып, басуга алып чыгып киткән ди. Менә кайда икән ул хозурлык, дөнья киңлеге! Ул җанга рәхәт һавасы, ул урман-сулары, ул кошлар сайравы! Андый вакытта чакма ташыдай Нәникәй тик кенә утыра аламы соң? Иң әүвәл ул җиргә сикереп төшкән дә шактый вакыт арба белән янәшә йөгереп барган. Шундый тиз йөгерә, тәгәрәп барган сыман гына элдертә икән бу.

— Улым, аргансыңдыр. Әйдә утырып бар, — ди икән карт.

Әтисенең тез башында әллә ни озак утыра алмаган Нәникәй. Кинәт сикереп торган да, дилбегә каешыннан чайкала-чайкала йөгереп үтеп, җирән кашканың ялларына ябышып, ике колагы арасына менеп тә баскан ди. Шундый биектә булуына куанып кычкырып та җибәргән бу:

— Һәй, эти!.. Әтием, менә мин кайда!..

— Сак бул, Нәникәем! Егылып төшә күрмә, — дигән этисе.

— Юк! Мин егылмыйм!

Ат бара, ә атның ике колагы арасында тирәюньне күзәтеп, Нәникәй бара. Күңеле хозурланып киткәнме, көмеш кыңгырау кебек чыңлап торган тавышы белән, тургай сыман иртәнге һаваны яңгыратып, кычкырып җырлап та җибәргән ди:

Имән чикләвеге кадәр
Булсам да үзем,—
Кыю да мин, тапкыр да мин,
Уңган да үзем...
Тра-ля-ля, тра-ля-ля,
Ля-ля-ля!..

— На-а, малкай!..

Нәникәйнең бу кыланмышларын күзәтеп барган карт түзмәгән:

— Болай булгач, улым, булдырасың икән! — дип мактаган ди аны.

Ут-малайга бу җитә калган, тагын да дәртләнеп:

— Әти! Әти, дим. Мин куркакмы, түгелме? — дип сораган ди.

— Юк, улым, бер дә куркак түгел. Нәкъ җырындагыча — бик кыю син.

— Мин әле тагын да кыюрак булырмын.

— Шулай итәрсең, улым. Кыюлык — ярты бәхет ди бит.

Ул арада олы юл буендагы басуларына барып та җиткәннәр болар. Карт шундук, җирән кашканы сукага җигеп, эшкә керешкән ди. Нәникәй дә ат башына менеп кунаклаган. Күпмедер сөргәч, суканы тырма белән алыштырганнар.

— Әти! Әтием, дим, бир, үзем тырмалыйм әле!.. — дигән ди Нәникәй.

— Булмаса булган икән, күрсәт әйдә һөнәреңне!

Шулай итеп, Нәникәй атны берүзе алып киткән. «Йә, малкай! Уңга борыл... Хәзер туры бар!» — дип, җирән кашканы гел каулап йөртә ди бу.

Ниһаять, әбәткә туктаганнар болар. Әти кешә нәни улын күкләргә чөеп мактый икән:

— Агач — җимеше белән, адәм — эше бе-

лән, дигәннәр борынгылар. Кулың эшкә ябыша икән, улым. Болай булгач, дөньям түгәрәкләнде.

— Эшләрмен дип әйткән идем ич! — дигән малай масая төшеп.

— Әйттең дә, эшләдең дә, улым. Егет сүзе бер була ди бит.

— Әти, этием, мин егетме?

— Синме? Егетнең дә егете син, улым.

Яңадан эшкә алынганнар болар. Карт сука калагын кайрарга утырган, ә Нәникәй җирән кашканың ике колагы арасына менеп баскан да:

— На-а, малкай!.. — дип кабат тырмаларга керешкән ди.

Шул вакыт олы юл өстендә тузан күтәрелгән. Карт кулын каш өстенә куеп караса — бер төркем гаскәри атлылар килә. «Кемнәр булыр икән болар? — дип уйлаган ул. — Менгән атлары да менә дигән, йөгән-иярләре дә, күзне камаштырып, елык-елык итеп тора».

Берничә җайдак карт ягына борылган. Әти кешенең күңелендә шом туган. Шулай да ул җәһәт кенә сикереп торган да атлыларга сәлам биргән:

— Юлларыгыз уң булсын, галиҗәнаплар!..

— Шулай булсын, хода бәндәсе! — дигән ди тегеләрнең башлыклары. Өстендә ука белән чигелгән чапан, башында кыйммәтле ташлар белән бизәлгән чалма, аягында исә алтын җеп бе-

лән чигелгән читек икән. Ә аты сыерчык канаты кебек чем-кара икән. Тик гаскәр башлыгының кашлары җыерылган, йөзе караңгы төн кебек ди. Бу хәлне күргән карт болай дип сорарга җөрьәт иткән:

— Бик кәефсез күренәсез, галиҗәнаплары, әллә берәр хәвеф-хәтәргә юлыктыгызмы?

— Юлыктык шул, — дип җавап кайтарган гаскәр башлыгы. — Юлым уңмады. Бик күп илләр гиздем, әмма эзләгән нәрсәмне таба алмадым. Бу исә минем өчен үлемгә тиң...

Карт, мөсафирның кайгысын уртаклашырга теләгәндәй, яңадан сорау биргән:

— Ни эзләгән идегез соң?

— Мин галиҗәнап шаһиншаһымызның баш вәзиремен, — дип башлаган ди затлы киенгән җайдак. — Бәлки ишеткәнсеңдер, аның Шаһинә исемле дөньяда тиңе булмаган бердәнбер сылу кызы бар. Әтисе кияү сайлауны кызның үз ихтыярына куйды: кем дә кем аны китергән бүләге белән гаҗәпләндерә, шаккатыра ала, кыз шуны кияве итәчәк. Кемнәр генә, кай илләрдән генә килмәделәр! Нинди генә бүләкләр китермәделәр мәгърур кызга! Ул, мин сиңа әйтим, кояшның бар нурын үзендә чагылдырган җәүһәр-

ләр дисеңме, ул фил сөягеннән ясалган, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән тәхетләр дисеңме, сузсаң җирдән айга җитәрлек асыл парчалар, көмеш тояклы, алтын яллы гүзәл аргамаклар дисеңме — берсе дә калмады! Әмма кияү булырга ниятләнеп килгән берсеннән-берсе гүзәл ил уллары, берсеннән-берсе баһадир ир-егетләр, ничек килгән булсалар, шулай кире китеп тә бардылар... — Бу сүзләрне әйткәч, баш вәзир, җанына җыелган моң-зарын чыгарып селеккәндәй, авыр итеп көрсенеп куйды.— Мин дә Шаһинәне үземнеке итмәкче идем... Үлеп гашыйкмын! Ул матур гөл сыман минем күз алдымда үсте, чәчәк атты. Үзенең гүзәллеге белән күңелемне җәлеп итте. Мин дә бәхетемне сынап карамакчы идем. Могҗизалы бүләк табу нияте белән иксез-чиксез юллар үттем, бик күп илләр гиздем. Тик ... таба алмадым. Шунлыктан, газиз башкаемны ташларга орырдай булып, өметсезлеккә бирелеп, кайтып килүем. Синең янга да: «Берәр могҗиза турында ишеткәне юкмы икән?» — дип туктавым иде.

— Андый хикмәтләрне күргәнем дә, ишеткәнем дә юк шул, галиҗәнаплары, — дип җавап кайтарган ди карт.

Затлы кунаклар китәргә җыенганда гына баш вәзир җир өстендә эшләп йөргән атка игътибар иткән.

— Сөбхан-ал-ла! — дигән ул. — Атыңны әй-

тәм әле, әллә үзе генә шулай җир сөреп йөриме?..

— Юк, — дип җавап кайтарган ди карт. — Атны улым йөртә.

— Улың?! Соң ат янында беркемне дә күрмим...

— Күрмәвегез гаҗәп түгел, галиҗәнаплар. Минем улым бик бәләкәй. Ә-нә ул, ат колаклары арасында басып тора.

Баш вәзирнең ике күзе дүрт булган ди.

— Бәрәкал-ла-а!..

Күрче! Аның алдында могҗизаның да могҗизасы лабаса!..

Вәзир шундук: «Улыңны миңа бир», — дип гозерли башлаган. Картка гомере буена җитәрлек мал-мөлкәт, алтын таулары вәгъдә иткән. Ә инде карт: «Ул бит минем бердәнберем, юанычым!..» — дигәч, вәзирнең йөзенә ерткыч төсе кергән ди.

— Малаең барыбер минеке булачак. Юкка карышма! — дип җикеренгән ди ул. Аннары алар турысына килеп җиткән аттан Нәникәйне эләктереп тә алган ди.

Нәникәйнең: «Әти!.. Әтием!.. Бирмә мине, бирмә!..» — дип үзәк өзгеч тавышы белән кычкырганы гына ишетелеп калган ди.

Ул арада баш вәзир Нәникәйне: «Чыелдама, таш сыбызгы!» — дип, затлы кулъяулыгына төреп куен кесәсенә тыгып та куйган ди.

Картның: «Галиҗәнаплар, шәфкатьле булыгыз, миһербаныгыздан ташламагыз!» — дип өзгәләнүенә атлы гаскәриләр игътибар итеп тормаганнар, картны гөрзи белән бәреп екканнар да китеп барганнар ди.

Карт аңына килеп: «Ләгънәт сезгә, мәлгуньнәр!» — дип, елый-елый аягына басканда, атлылар күптән инде күздән югалган булганнар.

Баш вәзир, күктән эзләгәнне җирдән таптым дип, куана-куана атын һаман алга чаптырган.

Юлдан чыгып өлгермәгән мөсафирларны таптап кына узган. Тизрәк кайтып җитеп, Нәникәй белән Шаһинәне генә түгел, падишаһның үзен дә шаккатырырга теләгән ул. Әй-йе, хәзер ул баш вәзир генә түгел, ә падишаһ кияве дә. Бәлки әле, тәхетнең хуҗасы да булыр...

Вәзир, шатлыклы хәбәрне җиткезеп алдан ук сөрән салдыру өчен, чапкын йөгерткән.

Вәзирне быргылар уйнатып бәйрәмчә каршылаганнар ди. Падишаһ хәтта тәхетеннән торып аягүрә баскан ди.

— Йә-ә турылыклы вәзирем! Безне ни белән шаккатырырсың да ни белән куандырырсың икән?

Тегесе бик эре кыяфәт белән Шаһинә алдында торган бәләкәй өстәл янына килгән дә куенындагы төенчеген чыгарып:

— Карагыз! Бу төенчектә моңарчы әле беркемгә дә күрергә язмаган җан иясе, ягъни менә бу малай! — дип, төенчекне чишеп җибәргән ди.

Шунда көтелмәгән хәл булган. Барысы да, яшен суккандай, катып калганнар. Чөнки өстәлдә көеп берничә җире тишелгән кулъяулык белән имән чикләвегенең буш оясы гына ята ди.

— Бу ни бу?! — дип үкергән падишаһ һәм каршысында торган өстәлне тибеп аударган ди. — Син нәрсә?.. Падишаһыңны мыскыл итәсеңме, аңгыра бәрән! Ахмак башың белән саубуллашасың киләме?!

Бу көтелмәгән хәлдән шашар дәрәҗәгә җиткән вәзир гөрселдәп җиргә ауган.

— Бөек падишаһым, бер генә юлга кичерә күр! Качкан бит ул, җүнсез!

Әлеге могҗизалы малайны җир астыннан булса да табып кайтырга вәгъдә иткәч, падишаһ вәзирне бер юлга кичергән ди. Башкисәр җәлладларын чакырмаган. Вәзир исә шул ук минутта, уклы-кылычлы гаскәрен ияртеп, Нәникәйне эзләргә киткән.

Чыннан да, кайда икән соң безнең Нәникәебез?

Иң әлек аның: кыю да мин, тапкыр да мин, дигән җырын искә төшерик. Тикмәгә генә җырламаган ул. Аннары Нәникәйнең Ут-малай булуын да онытмыйк. Аны кулъяулыгына төреп салган вәзир, алны-артны, уңны-сулны белмичә, атын куган да куган. Нәникәйнең йөрәге ярсудан, бер урынына биш тибеп, шундук ялкынга, ә үзе утлы күмергә әверелгән. Ул вәзирнең кулъяулыгын тишеп чыккан да атның җиргә җиткән ялы буйлап төшеп калган. Ызан буенда каңгыраеп утырган әтисе янына кайтып җиткәндә, җир өстенә эңгер дә иңеп өлгермәгән әле. Очрашкач, куанычларының бер дә чамасы булмаган ди.

Икенче көнне таң белән яңадан эшкә керешкәннәр болар. Нәникәй басуны бер тапкыр әйләнергә дә өлгермәгән, җаннарына шом салып, юл өстендә яңадан тузан өермәсе күтәрелгән.



Моны, беренче булып, җирән кашка колаклары арасындагы Нәникәй күргән.

— Әти!.. Әти, дим!.. Тагын алар!.. — дип хәбәр салган ул.

Карт та өнсез калган.

— Ах-х, балакай! Алар безгә шулай көн күрсәтмәс микәнни!.. — дигән ул.

— Әти!.. Әтием, качыйммы?.. — дип киңәш сораган Ут-малай.

— Кач, улым! — дигән карт.

Ай күргән, кояш алган Нәникәйне ат өстеннән.

Ул арада атлылар ажгырып килеп тә җиткәннәр.

— Малаең кайда?! — дип үкергән Вәзир, күзләреннән ут чәчеп.

Сакчылар җирән кашкага барып ябышкан: аны авызына кадәр ачтырып караганнар. Нәникәйне тапмагач, картка гөрзи белән органнар. Шул чак Ут-малай түзмичә:

— Тимәгез этигә!.. — дип, яшеренгән урыныннан, балчык кантарлары арасыннан, атылып чыккан.

— Әһ-һә-ә! Менә син кайда икән, ут борчасы!.. — дип шәрран ярган баш вәзир. Шундук Нәникәйне эләктереп алган да, читлеккә эләккәч ерткыч та юашлана дип, тимер тартмага шартлатып бикләп тә куйган ди.

Нәникәй җирдә аунап яткан этисенең: «Зо-

банилар!.. Юлбасарлар!..» — дип тегеләрне каргавын гына ишетеп калган.

— «Инде нишләргә?» — дип баш ваткан ди Ут-малай. Тимер тартмада һава җитмәүдән тыны кысыла башлаган. «Мин монда үләм бит»,— дигән ул.

Әмма югалып кала торганнардан түгел шул Нәникәй. Тартма эчендә сузылып чалкан яткан да, аяк-кулларын капкачына терәп, аны ачмак булган. Күпмедер тырышканнан соң, ни күрсен, капкач чак кына ачылган. Нәникәйгә шул

гына кирәк тә. Ул тиз генә түбәтәй урынына киеп йөри торган имән чикләвеге оясын шул ярыкка кыстырып та куйган ди. Шунда аның сулыш алуы җиңеләеп, күз аллары яктырып киткән.

Аннары әлеге тар ярыктан кысылып кына чыккан да вәзирнең кесәсеннән җиргә сикереп төшкән. Бу юлы да тимер тартма эчендә имән чикләвеге оясы гына калган. Зарар юк, дип үз-үзен юаткан Нәникәй, баш исән булса, түбәтәй табылыр...

Ут-малай тартмада утырганда атларын өер-

мә урынына куган вәзирләр шактый юл алырга өлгергән булганнар. Нәникәй төшеп калганда, кояш инде баю ягына авышкан. Караса, тирә-юнендә кара урман...

Менә шунда башланган аның хикмәтле хәлләре. Иң элек Нәникәйнең юлын киң елга бүлә. Әмма ул каушап калмый: ике-өч җәпле агач ала да шуны суга сөйрәп төшерә. Монысы көймә булыр, ди ул. Бака яфрагы өзеп алып җилкән куя. Шуның ярдәмендә елга аша йөзеп чыга. Ул арада караңгы да төшкән. Тирә-юнь бик шомлы булып калган. Әле ярый, шунда урман өстенә урак сыман ай калыккан.

Кая барырга да белмичә, аптырап торган Нәникәй. Ә кайнар йөрәге, ут кабынырдай булып, дөп-дөп итеп тибә икән. Әмма әллә ни озак баш ватып тормаган Ут-малай, атлар эзе буйлап кайту ягына йөгергән.

Нәникәй юл өстендә этисенең үргән чыбыркысына охшаган бер нәрсә күргән. Йөгереп кил-

гән шәпкә, теге нәмәстәнең өстенә сикереп тә менгән. Әмма аның, таларга теләгән ата каз кебек ысылдап, баш калкытуын күргәч, Нәникәй зур гына кара җылан өстендә басып торганлыгын абайлап алган. Ут-малайны бу бәладән җитез тәпиләре генә коткарып калган ди.

Ул арада урман өстендә йөзгән ай да болытлар арасына кереп югалган. Нәникәйнең нәкъ баш очында гына, бала елаганга охшап, шыксыз бер аваз яңгыраган. Ни күрсен, агачлар арасыннан аңа ике ут төбәлгән. Монысы тагын ни булыр? Шулай дип уйларга да өлгермәгән,

әлеге яшькелт утларның үзенә таба якынлашуын күреп алган. Нәни мөсафир чәчрәгән очкын тизлеге белән башына гөмбә эшләпәсен алып кигән. Шул вакыт аның өстеннән, һава ярып, олы гына төнге кош — мәче башлы ябалак очып үткән.

Маҗаралар моның белән генә бетмәгән. Инде урманнан чыктым дип кенә торганда, Нәникәй каршына мәкерле төлке килеп чыккан. «Менә шәп булды әле карын ялгап алырга!» — дип куанган ди ул, мәлгунь.

Хәйләкәр төлке, тешләрен ыржайтып, аңа ташлангач кына, Нәникәй утлы күмергә әверелеп өлгергән һәм тегенең очлы танавына барып та ябышкан. Төлке борыны пешүдән үрле-кырлы сикергән ди, качып киткәндә көлтә койрыгы гына чагылып калган ди.

Менә таң аткан, кояш чыккан. Нәникәй чәчәкле болыннар, хәтфәдәй кыр-басулар аша кайткан. Бу тирәдән Нәникәйнең туган җирләренә дә ерак калмаган инде. Тизрәк, тизрәк дип йөгерә торгач, Нәникәй кайтып та җиткән. Улын югалтканга санаган әтисе белән очрашкач, куанычларының бер дә чамасы булмаган ди.

— Улым! Нәникәем!.. Сине көтә-көтә хастага сабыша яздым!.. — дигән әтисе.

Ул вакытта инде баш вәзир дә падишаһ сараена кайтып җиткән. Бу юлы да аны, нәкъ бе-

ренче тапкырдагы кебек, җиз быргылар уйнатып каршылаганнар.

Баш вәзир сарай кешеләре алдында үзен бик горур тоткан. Бары тик падишаһ белән сылуларның сылуы Шаһинә алдында гына башын игән ди. Аннары, һуштан язарга барыгыз да әзерме, дигән кыяфәт белән, җыелган халыкны күздән кичергәч, тартманы ачып җибәргән...

Тынлык урнашкан. Баш вәзир кинәт, бу тынлыкны бозып, яраланган җанвар кебек кычкырып җибәргән.

— Падишаһым!.. Галиҗәнап хәзрәтләре... Шәфкатеңнән ташлама!.. Тагын качкан!.. Тагын бер тапкырга гына кичерә күр!.. — дип, патшаның аяк астына гөрселдәп ауган ди ул.

Ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җиткән падишаһ зәһәрлек белән:

— Син нәрсә, җаныңнан туеп йөргән бәндә?! Безне бүләгең белән түгел, ахмаклыгың белән шаккатырырга булдыңмы әллә?! — дигән.

Падишаһның аякларын кочып үбә торгач, тәки башын үз урынында калдырган ди баш вәзир. Бу юлы инде ул Ут-малайның үзен генә түгел, атын да алып кайтырга, хәтта җир сөреп тә күрсәтергә вәгъдә биргән, имеш.

Шулай иткән дә ул. Безнең Нәникәйне җирән кашкасы белән бергә алып кайткан. Урак кылычлы, очлы сөңгеле сакчылар юлның-юл буена Нәникәйне бер генә мизгелгә дә күздән яздырмаганнар ди.

Ниһаять, Нәникәйне, җирән кашканың ике колак арасына бастырып, падишаһ чыгып утыра торган мәрмәр тәхете каршысына китереп куйганнар ди. Ул халык, ул сарай хезмәтчеләре җыелган, бер дә исәбе-хисабы юк ди. Бераздан, сылу кызы Шаһинәне ияртеп, падишаһ та күренгән. Бөтен халык гөрселдәп җиргә ауган ди.



— Кая, бүләгеңне күрсәт, алайса!.. — дип әйтеп әйткән ди падишаһ.

Тик баш вәзир баскан җирендә таштай катып калган ди. Чөнки халык, шул исәптән вәзир үзе дә, падишаһка баш орган арада, Нәникәй күз иярмәслек тизлек белән шуып төшеп атның бәкәл йоны арасына кереп яшеренгән ди.

— Табыгыз!.. Хәзер үк табыгыз!.. Әле генә шунда иде, — дип үкергән ди баш вәзир.

Ялчы-хезмәтчеләр җирән кашканың карамаган, капшамаган бер генә җирен дә калдырмаганнар. Хәтта эре тарак белән ялларына кадәр тараганнар ди. Тик тоякларын, бәкәл тирәләрен карарга гына берсенең дә башына килмәгән.

Шунда йөзе төннән дә болайрак каралган падишаһ:

— Күп мыскыл иттең, җитте! — дип җикергән баш вәзиргә: — Бер тапкыр, могҗизалы бүләк дип, ертык яулык алып кайттың; икенчесендә — чүп-чар салган калай тартма; ә хәзер менә каршыма җил иссә дә аварга торган карт алаша китереп бастырдың. Минем кызыма ялы-тоягы саф көмеш атлар да китереп карадылар, андый бүләкләргә дә әйләнеп карамады ул! — дип әйтеп әйткән ди.

Ярсуы ахыр чиккә җиткән падишаһ, баш вәзирен зинданга ябарга, җил иссә дә аварга торган җирән кашканы патша сарае ишегалдыннан куып чыгарырга әмер биргән.

Ат та акыллы икән, падишаһка койрыгын болгап китеп барган. Ә Нәникәй җирән кашканың бәкәл йоны арасыннан чыгып яңадан атның колаклары арасына менеп баскан.

Җирән кашка өйгә таба җән-фәрманга чаба, ә басулар киңлегендә, тургай сайравын хәтерләтеп, җыр яңгырап кала икән.

Имән чикләвеге кадәр
Булсам да үзем;

Кыю да мин, хәйләкәр дә,
Уңган да үзем...
Тра-ля-ля, тра-ля-ля-ля,
Ля-ля-ля!..

Ат адәм баласының канаты ди бит. Болар бернинди хәвеф-хәтәрсез кайтып җиткәннәр. Шуннан соң аларны бүтән борчымаганнар. Тыныч кына яшәгәннәр. Нәникәй әле дә җир җимертеп эшли. Ә этисе исә аның тырышлыгына куанып бетә алмый ди.

Нәни укучым! Басулар киңлегенә чыкканда, син дә игътибар ит әле: Ут-малай, шук малай Нәникәйнең җыры ишетелмәсме? Тик тургай сайравы белән бутый күрмә үзен, яме!

◆

ББК 84 (2Р-Тат)-4
Х 35

Хәсәнов М. М.

Х 35 Ут-малай: Әкият.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 31 бит.
ISBN 5—298—00541—1

Х $\frac{4803010200-334}{М 132(03)-89}$ 48—88

ISBN 5—298—00541—1
© Татарстан китап нәшрияты, 1989.

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

ХАСАНОВ МАХМУД МАКСУДОВИЧ

МАЛЬЧИК-ОГОНЕК

Сказка

(на татарском языке)

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *М. Абитова*
Корректоры *М. Хәйруллина*

ИБ № 5498

Җыярга тапшырылды 18.05.88. Басарга кул куелды 9.11.88. Форматы 70×90¹/₁₆. Офсет кәгазе № 1. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,34. Шартлы буяу-оттиск 10,53. Нәшер-хисап табагы 2,27. Тиражы 50 000 экз. Заказ Е-273. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

Художнигы З. МӨХӘММӘТҖАНОВА

20 тиен.